*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2023-2024 нче уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 49**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Саңгырау тартыклардан гына торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
 1) [р], [л], [м], [н]
 2) [п], [к], [с], [ч]
 3) [з], [щ], [х], [һ]
 4) [ф], [т], [ш], [д]

2. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) валчык
2) тимераяк
3) тәрәзә
4) болынлыкта

3. *Юл* сүзендә ю хәрефе нинди аваз белдерүен билгеләгез. **(2 балл)**
1) [у] авазын
2) [йү] авазын
3) [йу] авазын
4) [ү] авазын

4. Юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
 1) алма
 2) уңыш
 3) каен
 4) тиен

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Татар хатын-кызларыны төсле җепләр белән чигелгән, сәйлән белән бизәлгән баш киеме*
1) калфак
2) бүрек
3) яулык

4) башлык

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Үз халкын сөймәгән*
1) аптырап утырган.
2) ерак киткән.
3) телен белгән.
4) башка халыкны да сөймәс.

7. Синоним сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
1) матур, чибәр
2) кайнар, салкын
3) сөйләшү, йөгерү
4) ак, кара

8. *Кар* сүзенә тамырдаш булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) карга
2) карлы
3) карандаш
4) кара

9. Юнәлеш килеше кушымчалары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) -ның/-нең
2) -га/-гә, -ка/-кә
3) -ны/-не
4) -да/-дә, -та/-тә

## II. Теоретик бирем.

Антонимнар турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(5 балл)**

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз һәм килеш кушымчасын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) урман | 1) -тан |
| Ә) китап | 2) -дан |
| Б) бала | 3) -нан |
| В) әти | 4) -нән |
| Г) энем | 5) -дән |

**Җавап :** ________________________

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Үрмәкүч челтәрдән өй үреп, агач башына (куйган / элгән / ясаган). Бөҗәкләр, сокланып:

- Нинди матур өй, безнең мондый матур өйне беренче тапкыр күрүебез, - дигәннәр.

Тик чебен генә бер сүз дә (сөйләмәгән / дәшмәгән / уйламаган). Аның ничек тә булса үрмәкүч оясын урлыйсы килгән һәм аны үрмәкүче белән күтәреп алып китмәкче булган. Тик үзе уралып калган, котылырга теләп чәбәләнгән саен ныграк кына (югалган / уралган / баткан) һәм һәлак булган.

Кеше (өенә / малына / матурлыгына) кызыксаң, шулай була ул.

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Тәр ... зәгә күз салдым –
Бик нык гаҗәпкә калдым:
Бозау х ... тле сап-сары эт,
... фрагын җы ... п талның,
Әй кереште күшәргә,
Инде миңа нишләргә? (*Ф. Тарханова*)

3. Шигырьдән *карадым* сүзенең синонимын күчереп языгыз. **(2 балл)**

________________________________________

________________________________________

4. *Нишләргә* сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз. **(4 балл)**

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

5. “Туган ягым” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. (**7 балл**)